Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге составына керүче Кызыл Чапчак торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2025 елның 22 ноябре № 5

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлегенең Кызыл Чапчак торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Кызыл Чапчак авыл җирлеге Кызыл Чапчак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире/хатыныннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче солдатлардан тыш, 2026 елда 4300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны:

– торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр җир өсте кичүләрен ремонтлау;

– торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

– яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту.

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлегенең Кызыл Чапчак торак пунктында гражданнар Җыенының 2024 елның 15 ноябрендәге 2 номерлы карары буенча су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлауга, төзүгә һәм ремонтлауга җыелган 600 000 сум күләмендәге үзара салым акчаларын торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга юнәлдерергә

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кызыл Чапчак авыл җирлеге башлыгы Б.В.Ильдарханов

НИЖНЕКАМСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
р.07-5881/27
Совет Краснокадкинского сельского поселения
Кызыл Чапчак авыл җирлеге советы
ИНН 1630003130